ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

29.08.2013 № 10-31/кс

Казан ш.

***«Таттеплосбыт» ААҖ китерә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Таттеплосбыт» ААҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Таттеплосбыт» ААҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, иректә файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.08.2013 № 10-31/кс
карарына кушымта

«Таттеплосбыт» ААҖ китерә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (ике компонентлы) | |
|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал |
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | «Таттеплосбыт» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | Түбән Кама муниципаль районы кулланучылары, шул исәптән: | | |
| | Торак секторында кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымы белән күрсәтелә)* | 20,07 | 1304,05 |
| | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 17,01 | 1105,13 |
| 1.2 | Зәй муниципаль районы кулланучылары, шул исәптән: | | |
| | Торак секторында кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымы белән күрсәтелә)* | 32,44 | 1304,05 |
| | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 27,49 | 1105,13 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм